Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Югары Акташ авылы башкарма комитеты
КАРАРЫ

№ 4 15 июль 2020 ел

Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен
анализлау тәртибен раслау турында

“Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Әлмәт шәһәр прокуратурасының 2019 елның 16 декабрь 1254п номерлы күрсәтмәсен карап,

КАРАР БИРӘМ:

1. Гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен анализлау тәртибен расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә: Татарстан Республикасы, Әлмәт районы, Югары Акташ авылы, Совет урамы, 15 йорт; «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үземдә калдырам.

Әлмәт муниципаль районы
Югары Акташ авылы башкарма
комитеты җитәкчесе А.В.Шатунов

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы
Югары Акташ авылы башкарма
комитетының 2020 елның
15 июль 4 номерлы
карарына 1 нче кушымта

Гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау
ТӘРТИБЕ

1. Әлеге Тәртип "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы N 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авылы башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Югары Акташ авылы башкарма комитеты кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тиешле чорда килгән, шул исәптән: Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасында теркәлгән "Электрон Хөкүмәт" телефоны буенча язма рәвештә, Интернет-кабул итү бүлмәсенә яисә электрон почта аша, гражданнарны шәхсән кабул итү барышында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше системасында теркәлгән "кайнар линия" телефоны буенча кергән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

2. Гражданнарның мөрәҗәгатьләренә йогынты ясый торган сәбәпләрне ачыклау һәм бетерү максатларында җирле үзидарә органнарының вәкаләтле вазыйфаи затлары кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясый.

3. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау елга 1 тапкыр башкарыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләргә анализда кергән, яңадан каралган һәм каралган язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләр саны, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив-хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат булырга тиеш.

5. Гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ җирле үзидарә органнары тарафыннан Әлмәт муниципаль районының Югары Акташ авыл җирлеге сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла.

6. Әлеге тәртипне бозуда гаепле вазыйфаи затлар кануннарда каралган җаваплылыкка тартылалар.

Әлмәт муниципаль районы
Югары Акташ авылы башкарма
комитеты җитәкчесе А.В.Шатунов